**Татарстан Республикасы**
**Минзәлә муниципаль районы**
**Хуҗамәт авыл башкарма комитеты**

# КАРАР

№ 18 03.04.2018 ел

Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге территориясендә
янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүгә
җәмәгать контролен оештыру турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон нигезендә, "Янгын куркынычсызлыгы турында" 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Хуҗәмәт авыл җирлеге территориясендәге янгыннардан халыкның һәм гражданнарның мөлкәтенең сакланышын тәэмин итү максатларында

**К А Р А Р Ч Ы Г А Р А М:**

1. Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә җәмәгать контролен оештыру турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

ТР Минзәлә муниципаль районы
Хуҗәмәт авыл җирлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы: Р.К.Әсхамова

1 нче кушымта
Карар
«03» 04. 2018ел № 18

Нигезләмә
Хуҗәмәт авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә җәмәгать контролен оештыру турында

1. Авыл җирлекләре территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, җәмәгать контролен оештыру турында карар кабул итә.

2. Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлегендә җәмәгать контроленең төп бурычы янгыннарны профилактикалауны, аларны сүндерүне һәм һәлакәттән коткару эшләрен уздыруны күзәтүдән гыйбарәт.

3. Җәмәгать контроле органнарына түбәндәгеләр керә:
- авыл Советы депутатлары;
- җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты;
- оешмалар хезмәткәрләре һәм гражданнар.

4. Җәмәгать контроле вәкилләре үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституция законнары, федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының норматив хокукый актлары һәм билгеләнгән тәртиптә расланган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән таяна.

5. Үз компетенциясе кысаларында җәмәгать контроле вәкилләре:
- җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары һәм гражданнар тарафыннан янгын куркынычсызлыгы таләпләрен тәэмин итүгә күзәтүне оештыралар һәм гамәлгә ашыралар;
- янгыннарның сәбәпләрен ачыклауда катнашалар;
- булган документларны анализлау нигезендә тикшерүләр башкару буенча гражданнарның оешмаларын һәм йорт биләмәләрен билгелиләр;
- федераль башкарма хакимият органнары, шул исәптән дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итәләр.

6. Җәмәгать контроле вәкилләре составы гомуми җыелышта (референдумда, җыенда) гади күпчелек тавыш белән аерым сайлана.

7. Җәмәгать контроле вәкилләре гражданнарның гомуми җыелышында (референдумда, җыенында) расланган хокукларга ия булалар.

8. Җәмәгать контроле вәкилләре түбәндәгеләргә бурычлы:
- янгыннарны профилактикалауны оештыруны, аларны сүндерүне һәм җирлек чикләрендә һәлакәттән коткару эшләрен башкаруны үз вакытында күзәтергә;
- Россия Федерациясе законнарын, оешмаларның һәм гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

- җирле үзидарәнең вазыйфаи затларын һәм гражданнарны тикшерүләр нәтиҗәләре белән таныштырырга;
коммерция серен һәм закон белән саклана торган башка серне сакларга.

9. Үз бурычларын тиешенчә үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җәмәгать контроле вәкилләре җәмәгать контроле составыннан чыгарылырга мөмкин.